**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Тинчәле авыл җирлегенең Шәйморза авылында гражданнар җыены карары**

14 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Тинчәле авыл җирлегенең Шәйморза авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елда Иске Тинчәле авыл җирлегенең Шәйморза авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, (юлларны ремонтлау),

- Шәйморза торак пункт территориясен төзекләндерү-кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу, (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

3. Җыен нәтиҗәләрен Иске Тинчәле авыл җирлегенең Шәйморза авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Тинчәле авыл җирлеге башлыгы _________ С.Р.Хәсәнов

Гражданнар җыены секретаре _________А.А.Гисмиева